ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш ); 2006, № 7 (I өлеш ); 2007, № 1 (I өлеш ), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш ); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш ); 2012, № 3, № 5 (I өлеш ); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5; Ватаным Татарстан, 2014, 17 июнь), түбәндәге эчтәлекле $37^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$37^1$ статья. **Җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаучыларга, җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә, алардан бу җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу турында мәгълүмат бирү**

Җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаучыларга, җир кишәрлекләрен төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә, алардан бу җир кишәрлекләрен дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу турында мәгълүмат бирү җир кишәрлекләрен аерып алу планлаштырылган көнгә кадәр кимендә бер ел алдан җирле үзидарә органы тарафыннан адресатка тапшырылуы турында белдерү кәгазе булган заказлы хат җибәрү юлы белән башкарыла, хатта түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) аерып алына торган җир кишәрлегендә төзеләчәк объектның исеме һәм билгеләнеше;

2) төзелеш объектын урнаштыру урынын алдан килештерү турындагы документның исеме һәм реквизитлары;

3) аерып алына торган җир кишәрлегендә төзеләчәк объектны урнаштыру күздә тотыла торган урын;

4) аерып алына торган җир кишәрлегенең мәйданы;

5) җир кишәрлеген аерып алуның килештерү өчен тәкъдим ителә торган сроклары, тәртибе һәм шартлары;

6) җир кишәрлеген төзелеш өчен бирүгә бәйле рәвештә бу җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу, шул исәптән сатып алу ихтималы турында хәбәр иткәннән соң җир кишәрлеге милекчесе, җирдән файдаланучы, җир биләүче һәм җир кишәрлеген арендалаучы җир кишәрлегендә төзелеш алып барган яисә аны башкача яхшырткан очракта, чыгымнарны һәм зыяннарны үзләре түләү куркынычы булу турында кисәтү.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 23 июле
№ 68-ТРЗ